СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Новая, д.52, с. Старое Чурилино, Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле авылы, Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

**Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карары**

**19 март 2016 ел** **№ 13**

**2016 елның 13 мартында үткәрелгән җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, 2016 елның 13 мартында референдумда тавыш бирү нәтиҗәләре нигезендә

«2016 елда Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 70 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 100 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы?

| № | № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар |
|---|---|---|---|
| 1 | Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү | мотопомпалар сатып алу:<br>- Иске Чүриле, Венета<br>- Иске Чүриле авылында янгын гидранты урнаштыру | 20 000<br>10 000 |
| 2 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - юлларга вак таш салу.;<br>Иске Чүриле авылы<br>Ашабаш авылы<br>Михайловка п. | 60 000<br>20 000<br>100 000 |
| 3 | Төзекләндерү эшләрен оештыру | - чишмә территориясен төзекләндерү;<br>Штерә авылы | 10 000 |
| | | барлыгы | 220000 |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә".

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Арча муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2016 елның 14 мартындагы 22 номерлы карарын теркәргә

Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы Г. Р. Заһидуллина

